# ТЕЛЕГРАММА № ____

| | |
|---|---|
| Куда и кому | Республика Башкортостан, Шаранский район, село Шаран, ул. 8 Марта, д.4 |
| (адрес) | Валиахметовой Светлане Сафиновне |

ПРАВИТЕЛЬСТВЕННАЯ

С.С.Вәлиәхмәтовага

Хөрмәтле Светлана Сафа кызы!

Бар гомерен һәм көч-егәрен газиз Татарстаныбызга һәм татар халкына хезмәт итүгә, мәдәниятебезне үстерүгә багышлаган талантлы, күренекле шәхес, Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты, оста гармунчы һәм чын халык җырчысы, милләтебезнең лаеклы улы – хәләл җефетегез Фән Гафис улы Вәлиәхмәтовның вакытсыз вафат булуы сәбәпле Сезнең, балаларыгызның һәм барлык туганнарыгызның тирән кайгысын уртаклашам.

Фән Гафис улы Вәлиәхмәтов зирәк, мөстәкыйль фикерле һәм игелекле кеше иде. Ул үзенең иҗат дусты – тальян гармунында үзе уйнап, үзе җырлап бөтен татар дөньясының олы мәхәббәтен казанды, ул башкарган җырларны халык шундук отып алып җырлый иде. Татар җыр сәнгатенең халыкчан традицияләрен саклаган, баеткан һәм дәвам иткән артистларыбызның берсе буларак, Фән Вәлиәхмәтов республикабыз тарихында, татар халкы күңелендә мәңгегә калачак.

Авыр туфрагы - җиңел, урыны оҗмахта булсын. Шушы кайгылы көннәрдә Аллаһ Тәгалә һәммәбезгә дә көч һәм сабырлык бирсен.

МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ПРЕЗИДЕНТЫ